СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №139 (7312) | 21 ноябрь, 1991 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Төзүчеләр сынатмый

Безнең 53 нче төзүмонтаж идарәсенең подряд буенча төзелеш эшләре күләме үткән 10 айга җиткерелгән план буенча 3 миллион 160 мең сум урынына 3 миллион 425,2 мең сум, ягъни 108,4 процентка үтәлде.

Шулай ук үзебезнең көч белән башкарыла торган эш планы 2 миллион 448 мең сум булса, ул 2 миллион 458,3 мең сум итеп, ягъни 100,4 процент булды.

Иван Александрович Моисеев җитәкләгән 1 участок төзүчеләре айдан-айга яхшы нәтиҗәләргә ирешәләр. Бу вакытка подряд эшләре планы 106,9 процентка, үз көче белән башкарган эш планының күләме 104,5 процентка үтәлгән. Әлбәттә, бу күрсәткечләрдә идарә буенча алдынгылардан саналган Владимир Андреевич Иванов җитәкләгән ташчылар бригадасының да саллы өлеше бар. Алар хәзер 60 квартиралы торак йорт төзү белән мәшгульләр.

Йосыф Галиевич Мостафин җитәкләгән II участок монтажчылары да хезмәттә сыната торганнардан түгел. Николай Александрович Сухарев бригадасы ташчылары участокта алдынгылардан санала. Боларга Аксубай районының «Сөлчә» колхозындагы 264 урынга исәпләнгән мәктәп, Чирмешән районында Киров исемендәге колхозда икешәр квартиралы торак йортлар төзү, Вишневая Поляна янында 160 урынга исәпләнгән пионерлар лагере һәм ит комбинаты заказы буенча 250 урынга исәпләнгән ашханәсе белән бергә фирма магазины төзелешләре керә.

Еллык йомгаклар да канәгатьләнерлек булсын өчен коллектив алдында булган резервларны эшкә җигеп тагын да тырышыбрак эшләү бурычы тора.

**Н. АНТОНОВА.**

Беренче кар төшкәнгә дә шактый вакыт үтте инде. Бер уйласаң, җәйне дә, көзне дә, кышны, язны да көтеп алабыз, аларның тизрәк җитүен телибез. Әшуның белән беррәттән, гомерләрнең су агышы кебек акканын гына искәрмибез.

Япь-яшь кызлар буларак Лидия белән Валентина да беренче мәртәбә товарлыклы-сөтчелек фермасына эшкә килделәр, аның авырлыкларын үз җилкәләрендә тәүге тапкыр татып карадылар. Сыер савучы хезмәтен һич тә җиңел димәсләр иде.



Хәер, хәзер фермада күп нәрсәләр үзгәрде, Лидия белән Валентина да олыгайдылар. Икесенең дә үз гаиләләре бар. Лидия Николаевнаның ире Николай Аркадьевич та терлекче булып эшли, ә Валентина Николаевнаның иптәше Николай Васильевич исә атлар карый.



Бүгенге көндә «Россия» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасында җәелдерелгән ярышта Анна Степановна Портнова беренче урында барса, икенче һәм өченче урыннарны Валентина Николаевна Наумова һәм Лидия Николаевна Яллина үзара бүлештеләр.

Валентина Николаевна үз карамагындагы һәр сыердан агымдагы елның 10 аенда 3685 килограмм сөт сауса, Лидия Николаевнаныкы—3567 килограмм.

Уңган сыер савучылар дүртмеңчеләр сафына басуларына да шикләнмиләр.

Рәсемнәрдә: «Россия» колхозының сыер савучылары Лидия Николаевна Яллина һәм Валентина Николаевна Наумованы күрәсез.

## Ишеттегезме әле...

x x x

Зур байлыкка ия булган илле Мәскәү баеның 51 проценты, СССРда законнарны бозмыйча гына бизнес белән шөгыльләнү мөмкин түгел, диләр. Бу кешеләрнең 40 проценты элек алыпсатарлык белән шөгыльләнгән. 40 проценты күләгәле бизнес белән таныш, 22 проценты хокук саклау органнары белән очрашкан.

90 проценты төрле дәүләт инстанцияләренә ришвәт бирмичә генә бизнес белән шөгыльләнеп булмый дип уйлый. Мәскәү миллионерларының башкарма комитет хезмәткәрләренә, финанс-контроль органнарына, таможня кешеләренә төрле дәрәҗәләрдәге халык депутатларына, милициягә һәм БХСС әгъзаларына ришвәт бирә.

x x x

Кушма Штатларда 58 миллиардер яши. 1,6 миллион кешенең мөлкәте ким дигәндә миллион доллар белән исәпләнә. Әмма хәзер байлык турында күзаллау үзгәрде, һәм күпләр рәхәт чигеп яшәү өчен миллион доллар гына җитми дип уйлый.

x x x

Бер Мәскәүдә генә дә 2,5 мең кеше күп миллионлаган байлыкка ия дип исәплиләр. Миллионерларның уртача яше 20—55 яшь. Күпчелеге югары белемле. 15 проценты—элеккеге эшчеләр. Байтагы—фәнни-техник белемле кешеләр.

x x x

Совет миллионерлары арасында социологлар өч типны аерып куя. Беренче тип— элеккеге номенклатура. Кагыйдә буларак, алар арадашлык, халыкара туризм, компьютерлар белән шөгыльләнә.

Икенче тип—кооперация турында закон кабул ителгәннән соң килгән кешеләр.

Өченче тип—элеккечә күләгәдә калырга омтылучы картлар, ветераннар.

Сораштыру нәтиҗәләре буенча социологлар миллионерларның якынча яшәү минимумын ачыкладылар: аларның күпчелеге ашау-эчүгә айга уртача бер кешегә мең сум тота. Ризыклар— базардан, кием-салым —коммерция кибетләреннән. Күңел ачуга айга 2,5 мең китә. Миллионер хатыннарының өчтән бере эшләми. 33 проценты хәмерне авызына да алмый. 35 проценты һәр көнне диярлек ресторанда була.

Совет миллионерының уртача эш көне 13 сәгать.

x x x

Эшсезләрнең 55 проценты — хатын-кызлар. 192 мең кешене промышленность, 28 меңен авыл хуҗалыгы, 34 меңен транспорт бушаткан.

x x x

1992 елның мартыннан Эстониядә квартир хаклары өч тапкырга күтәрелә.

x x x

Бер атна газсыз утырганнан соң, ниһаять Ереван өйләренә газ килде.

x x x

Якут-Саха ССР Мәскәүгә алмаз һәм алтын җибәрә башлады. Бу байлык инде хәзер таркалган Союзга түгел, Россиягә тәгаенләнгән. Сентябрьдә валюта чималын җибәрү туктатылганнан соң Якутиядә 5 мең тонна алтын җыелган икән.

x x x

Калуга шәһәрендә фатирлар сату аукционы үткәрелде. 2 бүлмәле фатир 260 меңгә бирелде. Фатир сатып алырга теләүчеләр арасында җирле халык кына түгел, Литвадан, Молдовадан, Урта Азиядән кайтучылар байтак.

x x x

Николаев шәһәрендә иң нәни «гүзәлләр» конкурсы үткәрелде. Бу исемгә 8 яшьлек Аня Пасечник лаек булды. Аняны чыннан да патшалар бүләге көтә иде—Япониядә эшләнгән төсле телевизор һәм видеомагнитофон.

## Комсомол хәзергә калды

19 ноябрьдә район Советының утырышлар залында ВЛКСМ район комитеты пленумы булды.

Катнашучыларның күбесе анда җыелганда бу пленум район комсомол оешмасы тарихында соңгысыдыр дигән фикердә булгандыр дисәм, һич тә хата булмас. Чөнки күбесе: «Партия юк, шуңа күрә аңа резерв та кирәкми»,—дигән фикердә торалар. Сүлпәнлек, залның битарафлыгы (югыйсә бит монда яшьләр лидерлары, танылган, һич югы сайланып куелган җитәкчеләр җыелган иде). —нәкъ менә шуны күрсәтте дә. Әмма комсомол белән хушлашырга иртәрәк булып чыкты әле. Районда ВЛКСМ членнарын яңадан теркәү үткәрелгән һәм 5560 комсомолдан 5се яңадан теркәү турында гариза биргән. Әмма 5 кеше—бу инде яшәргә хакы булган кечкенә генә оешма дигән сүз.

Пленумда комсомол бетәргә тиешме, әллә яшәргә тиешме дигән мәсьәлә күтәрелгәч, тавыш бирү йомгаклары бик тә кызыклы булып чыкты; залда утыручылар комсомолда калырга теләмәсәләр дә (яңадан теркәүдә катнашмадылар), куелган мәсьәләгә уңай җавап бирделәр. Әмма моның чын күңелдән әйтелгән сүзме, әллә үз-үзләрен «фаш итмәү» өчен генә бирелгән җавапмы икәнлеген аңлавы кыен иде. Ничек кенә булмасын, комсомолны хәзергә бетермәскә дигән карар кабул ителде.

Хәзергә дигән сүзне—комсомол оешмасының материаль базасында политикадан читтә торган, яңа яшьләр оешмасы булачак дип аңларга кирәк. Аның төп максаты яшьләр мәнфәгатен яклау, аларның ял сәгатьләрен оештыруга юнәлтеләчәк.

Яшьләрне ничек итеп политикадан читләштерү мөмкиндер—анысы да әлегә билгесез. Бер идеологиягә алмашка һичшиксез икенчесе килер. Бушлык булмаячак. Районда политик яшьләр партиясе төзергә тәкъдим белән чыккан (чынлыкта инде ул республикада «Азатлык» партиясе буларак яшәп тә килә) җирле СПТУ вәкилләренең, яшьләрнең чыгышлары шуңа раслау булып тора.

—Комсомол —үтелгән этап. Капитализм килсә —комсомолга анда урын юк. «Коммунистик Союз» дигән атама үзе үк яшьләрне куркытып тора,—дип саныйлар алар.

Яшь буын үсте һәм олыгайды. Хәзер «Исәнме, таныш булмаган яшь буын» дип әйтергә генә кала. Бу яшьләрнең тормышка үз карашлары, үз принциплары бар. Алар боларны яшермичә, һәркем ишетелерлек итеп сөрән салалар. Һәм аларның аһәңен ишетми мөмкин дә түгел. Әгәр яшьләрнең энтузиазмы, яшьлек ялкыны җәмгыятькә файдага түгел, ә зыянга булса, бу бик кызганыч, билгеле.

Пленумда 42 нче республика конференциясенә делегатлар сайлануын әйтәсе генә кала. Алар — Мичурин исемендәге колхозның спорт методисты И. Б. Храбров, ВЛКСМ райкомының беренче секретаре Н. М. Мөхәммәтҗанов, мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара предприятиедән В. Н. Шәйхетдинов, ВЛКСМ райкомының икенче секретаре вазифаларын башкаручы Ә. Х. Шәяхмәтов.

**Г. ХӘЛИУЛЛИНА.**

# Район бюджетының 1991 елның 9 аенда үтәлеше турында мәгълүматлар

Районның агымдагы елның 9 аенда билгеләнгән бюджеты керемнәр буенча 118,7 процентка үтәлгән. Планнан тыш район бюджеты керемнәренә өстәмә рәвештә 1747,0 мең сум күләмендә акча тотылган. Шул ук вакытта биш чыганактан (болар— әйләнештән керүче салымнардан килгән акча, индивидуаль хезмәт эшчәнлеге өчен салым, урман доходы, дәүләт налогы, эшкә яраклы үзагачтан файдаланган өчен түләү) 1114,9 мең сум күләмендә керем алынып бетмәде.

Агымдагы елның тугыз аенда барлык субъект предприятиеләре буенча табыш салымы җирле бюджетка пландагыдан 869,8 мең сумга күбрәк керде.

Быелгы елның 1 октябренә булган мәгълүматлар буенча районда 14 кооператив эшли, ә аларда 296 кеше шөгыльләнә. Алар 3213,2 мең сумлык продукция җитештергәннәр һәм хезмәт күрсәткәннәр. Бу исә узган елның шул чоры белән чагыштырганда 1425,3 мең сумга күбрәк. Алар шушы отчет чорында 763,2 мең сумлык табыш алганнар һәм әлеге табыштан кергән салым 132,8 мең сум тәшкил иткән. Әмма кооперативларның эшендә кимчелекләр дә юк түгел. Күпчелегенең «Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре» хезмәт турындагы законнарга җавап бирмиләр; хезмәткә түләү, фондлар, кооператив әгъзаларының материаль җаваплылыгы турындагы положениеләр гамәлдәге таләпләргә яраклаштырылмаган.

Районның экономик хәле 1991 елның 1 октябренә түбәндәгечә: барлык төр предприятие һәм оешмаларның, бюджетлы учреждениеләрнең счетларында калган акчалар узган ел белән чагыштырганда 16723,1 мең сумга артканнар.

Предприятие һәм оешмаларның партнерларына булган бурычы 3700,1 мең сум тәшкил итә һәм бу узган елгыдан 1838,1 мең сумга артыграк;

банклар тарафыннан предприятие һәм оешмаларга озак сроклы һәм кыска сроклы кредитлар бирелгән. Аларның күләме 90156,3 мең сум тәшкил иткән.

Район колхозлары һәм совхозларының счеттагы акчалары узган ел белән чагыштырганда 3790,0 мең сумга кимегән. Узган ел аларның кыска сроклы ссудалар буенча бурычлары булмаган, ә быел мондый бурыч 13086,0 мең сум тәшкил итә. Колхоз һәм совхозларның партнерларына булган бурычлары да быел 289,0 мең сумга арткан.

Март аеннан башлап, ваклап сату бәяләре күтәрелүгә бәйле барлык түләүләр РСФСР республика бюджетыннан каплана. Ә кайбер колхозлар (мәсәлән, «Родина», «Игенче, «Большевик», XXI партсъезд исемендәге, «Чишмә», «Москва», «Үрнәк», «Заря», Кузнецов исемендәге, «Чирмешән», «Ленинский путь», «Беренче май») үзләренең финанс кыенлыклары булуга карамастан, август һәм сентябрь айлары өчен компенсация түләү чыгымнарын үз счетларына яңадан кайтармаганнар.

**Отчет чорында район халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү производство идарәсе** 20,9 мең сум күләмендә зыянга эшләгән, ә өченче кварталда алар бу зыянны киметүгә ирешкәннәр. Көнкүреш хезмәте күрсәтүнең төп 19 төреннән 10сы табышлы, ә 9ы зыянга эшли.

**Күптармаклы производство предприятиесе** шушы вакыт эчендә зыянга эшләвен 204,8 мең сумга киметкән, хезмәт күрсәтү планын 9 айда 124,9 процентка үтәгән. Отчет чорында бу предприятиегә бюджеттан 1304,2 мең сум акча бирелгән. Шул исәптән 421,2 мең сумы шәһәрне төзекләндерүгә, 197,5 меңе җылылык өчен түләү тарифларындагы аерманы каплауга, 679,5 меңе фондлар булдыру һәм зыянны каплау өчен дәүләт дотациясе буларак тотылган.

**Норлат-Октябрь автомобиль юллары төзү һәм ремонтлау идарәсе** үзенең планын 111,9 процентка үтәгән, 9 айда 471,3 мең сум табыш алган.

**Икмәк заводы** отчет чорында 303,5 мең сумлык табыш алган. Әлеге табыштан салым 87,3 мең сум тәшкил иткән, шуның 58,8 меңе бюджетка кергән.

**Район ягулык белән тәэмин итү конторасының** баланс табышы 9 айда 67,4 мең сум булган. Бюджетка кертелергә тиешле салым күләме 25,2 мең сум тәшкил иткән. Ә чынлыкта 1 октябрьгә шуның 15,8 меңе генә кертелгән.

**Кино челтәре дирекциясе** буенча тулаем җыем планы 108,4 мең сум тәшкил итсә, фактта исә 137,7 мең сумлык эш башкарылган. Планнан тыш зыян 12,0 мең сум тәшкил иткән. Әмма киноҗайланмаларның эшләмәгән көннәр саны узган елның шушы чорындагыдан быел 625 көнгә кимрәк.

**Район халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү идарәсендә** 1990 елның августында әлеге тармакның хәлен финанс ягыннан яхшырту буенча эшчәнлекләрен тикшерү оештырылган иде. Тикшерү нәтиҗәләре 1990 елның 30 августында район Советы башкарма комитеты утырышында да каралды. Һәм җитешсезлекләрне бетерү буенча карар да кабул ителгән иде. Әлеге тикшерүдән соң 1 ел вакыт узды. Бу вакыт эчендә нәрсә үзгәрде соң?

Идарә хезмәт күрсәтү сферасын киңәйтү мәсьәләләре белән шөгыльләнми. Мебельләр ясау һәм ремонтлау, шәхси җиңел автомобильләргә хезмәт күрсәтү цехлары әле бүген дә оештырылмаган. Көнкүреш хезмәтләре күрсәтүгә өйдә эшләүчеләр тартылмый.

Суыткычлар һәм башка төрле көнкүреш техникасын ремонтлау буенча участокның да эше канәгатьләнмәслек хәлдә. Көнкүреш техникасын кабул итеп алганда квитанцияләр дөрес тутырылмый. Участок үзе суыткычлар белән шыгрым тулган, заказларның үтәлү срогы турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Запас частьләр булмау сәбәпле, кайбер суыткычлар монда икешәр ел торалар инде.

Аяк киемнәре төзәтү цехында үткәрелгән тикшерү вакытында мастер Н. М. Минганиевның эш өчен кергән акчаны июль аеннан бирле идарә кассасына тапшырмаганлыгы ачыкланды. Бу уңайдан акча тапшырылсын өчен идарә җитәкчелеге әле бүгенгәчә бер чара да күрмәгән.

Киемнәр тегү ательесында үткәрелгән тикшерү прейскурантлардан дөрес файдаланмау яки фасонны үзгәртү нәтиҗәсендә заказчылардан акчаны күбрәк каеру һәм киресенчә кимрәк тә алу очракларын ачыклады.

Башкарма комитет карарының ничек үтәлешен тикшерүләр әлеге тәкъдим ителгән чараларның кәгазьдә генә калуын, хезмәт күрсәтүне яхшырту буенча бер генә үзгәреш тә булмавын күрсәтте.

Салым инспекциясе тугыз айда районның 25 предприятие һәм оешмасында, 20 колхозда һәм 16 кооперативта тикшерүләр үткәрде. Бюджетка өстәмә рәвештә 180,0 мең сумнан күбрәк акча күчерелде. Шуның 67,2 меңе финанс санкцияләре рәвешендә алынды.

Тикшерүләр нәтиҗәсендә бухгалтерлык эшен алып баруда закон бозулар һәм кимчелекләр булуы ачылды. «Экос» һәм «Пластик» кооперативларында һәм «Чирмешән» колхозында урындагы кешеләр административ җаваплылыкка тартылды.

Ел дәвамында кредит бурычларын вакытында түләмәү очраклары ачыкланды һәм нәтиҗәдә җирле бюджетка өстәмә рәвештә 30 мең сумнан артыграк акча керде.

Бу чорда 113 оешмада, колхозда һәм совхозда эшче һәм хезмәткәрләрдән керем налогын тотып калуның дөреслеге тикшерелде. Нәтиҗәдә 1018 счет буенча 34,5 мең сум акчаның алып җиткерелмәве ачыкланды.

Район бюджетының чыгымнар өлеше тулаем алганда 81,4 процентка үтәлгән. Авыл Советлары буенча ул 106,7 процент, шәһәр Советы буенча—98,3, ә район Советы буенча 72,9 процент тәшкил итә.

Халык хуҗалыгы чараларын финанслауга каралган чыгымнар планы 93,8 процентка үтәлгән.

Социаль-культура чаралары буенча тулаем алганда 88,9 процентка чыгымнар тотылган. Шул исәптән —халык мәгарифе чыгымнары—93,4, культура —71,2, массакүләм информация чаралары—100; сәламәтлек саклау —85,2, физик культура буенча 80 процент тәшкил иткән. Үзләштерелмәгән процентлар исәбендә алынмаган җиһаз һәм инвентарь; үткәрелмәгән капиталь ремонт эшләре күздә тотылуы һәркемгә аңлаешлы. Моннан тыш сәламәтлек саклау өлкәсендә ул дарулар белән тәэмин итүнең, стационар авыруларның туклануын оештыруның күздә тотылганнан түбәнрәк дәрәҗәдә булуы белән аңлатыла.

1991 елның 1 гыйнварыннан Зирекле авылында 25 баланы үз эченә алган балалар бакчасы ачылу күздә тотылган иде. Әмма аның әле бүгенгәчә ачылганы юк. 1991 елның гыйнварына булган ирекле калдыклар хисабына халык мәгарифе, культура, сәламәтлек саклау, социаль-тәэминат өлкәләренә өстәмә акча билгеләнде.

Дәүләт ваклап сату бәяләре артуга бәйле рәвештә агымдагы елның 9 аенда РСФСР республика бюджетыннан безнең район территориясендәге барлык предприятие, учреждение һәм оешмаларга эшче һәм хезмәткәрләргә бирелә торган компенсация хисабына 6135,1 мең сум акча күчерелде.

Җирле бюджеттан III кварталда предприятие, оешма һәм учреждениеләргә пенсия һәм пособие алмаучы балалар өчен айлык түләүләр һәм балалар киемнәре кыйммәтләнүгә бәйле түләүләр өчен 304,5 мең сум акча күчерелде. Шулай ук балалы гаиләләргә ярдәм йөзеннән мәктәп формасы һәм башка төрле киемнәр алу өчен елга бер тапкыр бирелә торган түләүләр җирле бюджет хисабыннан башкарылды.

**Р. БИЛАЛОВ,**
халык депутатларының район Советы башкарма комитетының финанс бүлеге мөдире.

■ *Ничек яшисең, авыл?*

## Ашханәбез нуры

Ашханәбез нуры ул, дип мин Бикүле урта мәктәбе ашханәсендә эшләүче, тәмле ашлар остасы Мәстүрә апаны атыйм.

Мәстүрә апа инде берничә ел мәктәп ашханәсендә эшли. Ачык, нурлы йөзле бу апа безне көн дә җылы сүзләр белән каршы ала. Ашханәбез заманча җиһазланган. Азык-төлек ягыннан туган колхозыбыз ярдәм итә. Без көн саен кайнар аш, ипи чәй белән тәэмин ителәбез. Ике яки өч дәрес тәмамланган төшкә безгә кайнар аш әзер. Яше белән Мәстүрә апа мәктәпнең барлык укытучыларыннан да олы. Ул һәркемгә ихтирамлы, тәмле тел белән эндәшә.

—Сез, Мәстүрә апа, тәмле ашлар пешерүче генә түгел, ягымлылык тәрбияләүче буларак та үрнәк безгә,—диләр аңа яшь укытучылар.

Ак халатлы, нурлы йөзле, тәмле телле Мәстүрә апабыз чыгарылыш класс укучыларыбызга һөнәр сайлауда да ярдәм итә. Шуңа күрә ел саен күп кенә укучылар «Повар-кондитер» һөнәрен сайлап укуларын дәвам иттерәләр.

—Рәхмәт сезгә, Мәстүрә апа. Олы хөрмәткә лаек кеше сез. Эшегездә уңышлар сезгә.

**Б. МИННЕГОЛОВА.**
Бикүле авылы.

## ҺАВАДА ЙӨЗҮ





Һавада йөзүнең 30 нчы еллар шау-шуыннан һәм ярты гасыр тынлыктан соң һава шарларында очу кабат модага керде. Мәскәү һәм Санкт-Петербург, Вильнюс (конкурстан тыш), Алма-Ата, Рязань һәм Иркутск очучылары кабат ярышалар.

Курск җирендәге зур булмаган Рыльск шәһәре һава турнирларын үткәрүдә лидерлыкны үз кулына алды. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, беренче буларак, һавада йөзүчеләр мәктәбе ачыла, ул җирле авиаколледж базасында эшләячәк. Аның коллективы ике тапкыр бөтенсоюз турнирларында катнашучыларны кабул итте инде. Икенчесе, сентябрьдә уздырылганы, СССР чемпионаты дәрәҗәсендә узды, өстәвенә ул ачык чемпионат булды. Конкурстан тыш катнашучы Литва спортчыларын санамаганда, һавада йөзүче энтузиастларның күпчелеге бүген Казахстан башкаласында яшиләр. Алматалылар илнең беренче чемпионатында җиңүчеләр булдылар, аны үткәрүдә Индия һәм АКШтан килгән кунаклар да катнашты.

Рәсемдә: һава шарлары белән ярышып;

НЛО һөҗүме.

(ТАСС фотохроникасы).

